**ГЛАВА
СРЕДНЕКАМЫШЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРТА КАМЫШЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Урта Камышлы **КАРАР**

**«30» октябрь 2019 ел** **№ 1**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Кече Камышлы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Урта Камышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Кече Камышлы торак пунктында Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Кече Камышлы авылы, К.Маркс урамы, 32 нче йорт адресы буенча урнашкан Кече Камышлы авыл клубында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 2019 елның 13 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Кече Камышлы торак пунктында Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Кече Камышлы авылы, К.Маркс урамы, 32 нче йорт адресы буенча урнашкан Кече Камышлы авыл клубында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын 2019 елның 13 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен Кече Камышлы авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлү тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Keче Камышлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендәге юлларны ремонтлау.
- су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару
- роторлы чапкыч сатып алу.

«ӘЙЕ» «ЮК».

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Кече Камышлы авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы Н. А. Баймяшкина